**СОВЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615, с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 2-91-45

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422615, Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 2-91-45

**2024 елның 29 феврале** **11 номер**

**КАРАР**

**«Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау, һәм Чирпы авыл җирлеге муниципаль торак фонды йортларында социаль наем шартнамәсе буенча мондый гражданнарга торак урыннар бирү турында» 2011 елның 15 декабрендәге 32 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Граждан кодексы, "Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Чирпы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау, һәм Чирпы авыл җирлеге муниципаль торак фонды йортларында социаль наем шартнамәсе буенча мондый гражданнарга торак урыннар бирү турында» 2011 елның 15 декабрендәге 32 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр, ветераннар һәм яшьләр эшләре буенча комиссиягә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Чирпы авыл җирлеге Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы** **Р.В. Мышева**